ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МОНАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ
ЯҢА КОКШАН АВЫЛЫНДА
ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

2019 елның 29 ноябреннән № 4

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Монаш авыл җирлегенең
Яңа Кокшан авылында гражданнар җыены
нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монаш авыл җирлегенең Яңа Кокшан авылында гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монаш авыл җирлегенең Яңа Кокшан авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертергә, 1-2 төркем инвалидларга һәм Бөек Ватан сугышында катнашучыларга аның күләмен 250 сум итеп билгеләп куярга.

2. Үзара салым акчаларын түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

1. Яңа Кокшан авылында чишмәне төзекләндерү;
2.Җирлек территориясендә кар чистарту;
3. Тирәнлек насосын сатып алу..

3. Яңа Кокшан авылының мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru «Монаш авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Монаш авыл җирлеге башлыгы Р.Ф. Иосифов